**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы**
**Чуаш-Кичүе авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

2018 елның 31 мае 11 №

**Әлки муниципаль районы Чуаш-Кичүе авыл җирлеге Советының 2014 елның 29 декабрендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чуаш-Кичүе авыл җирлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 38 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

2017 елның 28 мартындагы «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 48-ФЗ номерлы Федераль закон белән кертелгән үзгәрешләр нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чуаш-Кичүе авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чуаш-Кичүе авыл җирлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 17 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Чираттагы финанс елына һәм план чорына җирлек бюджеты проектын төзү нигезләнә:

Россия Федерациясендә бюджет сәясәтен (бюджет сәясәтенә таләпләр) билгели торган Россия Федерациясе Федераль Җыелышына (Собраниесенә) Россия Федерациясе Президенты юлламасы нигезләмәләренә;

Россия Федерациясенең бюджет, салым һәм таможня-тариф сәясәтенең төп юнәлешләренә (Россия Федерациясе субъектлары бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре, муниципаль берәмлекләрнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре);

социаль-икътисадый үсеш фаразына;

озак сроклы чорга бюджет фаразына (бюджет фаразы проекты, бюджет фаразы проектына үзгәрешләр);

дәүләт (муниципаль) программаларга (дәүләт (муниципаль) программа проектлары, күрсәтелгән программаларга үзгәрешләр кертелгән проектлар).»

- 18 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Җирлекнең социаль-икътисадый үсеше фаразы җирлекнең башкарма комитеты тарафыннан хуплана һәм җирлек бюджеты проектын, Россия Федерациясенең бюджет, салым һәм таможня-тариф сәясәтенең төп юнәлешләрен (Россия Федерациясе субъектларының бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре, муниципаль берәмлекнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре) кертеп, бер үк вакытта җирлек Советына җибәрелә.»

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны "Интернет" челтәрендәге Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырып, бастырып чыгарырга.

Әлки муниципаль районы
Чуаш-Кичүе авыл җирлеге
Советы Рәисе: И.А.Мамбетова